ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ **КАРАР**

22.12.2021 с. Муслюмово № 628

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрендә мөмкинлекләре чикләнгән һәм инвалид балаларга түләүсез ике тапкыр бушлай туклану бирү тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Уставы һәм Мөслим муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрендә мөмкинлекләре чикләнгән һәм инвалид балаларга социаль ярдәм күрсәтү максатыннан Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрендә мөмкинлекләре чикләнгән һәм инвалид балалар өчен бушлай ике тапкыр бирелә торган туклану бирү тәртибен яңа редакциядә расларга (1 нче кушымта).
2. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының «Мөслим муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрендә мөмкинлекләре чикләнгән һәм инвалид балаларга ике тапкыр бушлай туклану бирү тәртибен раслау турында» 2011 ел, 22 октябрь, 484 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.
3. "ТР Мөслим муниципаль районы мәгариф идарәсе" муниципаль казна учреждениесе җитәкчесенә “Мөслим муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрендә мөмкинлекләре чикләнгән һәм инвалид балаларны ике тапкыр бушлай туклану белән тәэмин итү турында" Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы башкарма комитеты карары нигезендә расланган тәртипкә туры китереп, мөмкинлекләре чикләнгән һәм инвалид балаларга түләүсез ике тапкыр бирелә торган туклануны тәэмин итәргә.
4. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районы һәм «ТР Мөслим муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенең рәсми сайтында урнаштырырга.
5. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль-мәдәни үсеш буенча урынбасары Бәдретдинова М. Р. йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе **А.Р. Хуҗин**

ТР Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының
2021 ел, “22” декабрь
№ 628 санлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында мөмкинлекләре чикләнгән һәм инвалид балаларга ике тапкыр бушлай туклану бирү
ТӘРТИБЕ

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге тәртип Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында мөмкинлекләре чикләнгән һәм инвалид балаларга (алга таба-мөмкинлекләре чикле һәм инвалид балалар) ике тапкыр бушлай туклану шартлары булдыру максатларында эшләнде.

Әлеге тәртип мөмкинлекләре чикле һәм инвалид балаларга ике тапкыр бушлай туклану бирү механизмын, ике тапкыр бушлай туклану бирү белән бәйле чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итү чыганакларын, мөмкинлекләре чикләнгән һәм инвалид балаларга ике тапкыр бушлай туклану бирү буенча контроль һәм җаваплылыкны билгели.

1.2. Мөмкинлекләре чикле һәм инвалид бала - физик һәм (яки) психологик үсештә җитешсезлекләре булган, психологик-медик-педагогик комиссия (алга таба-ПМПК) тарафыннан расланган һәм белем алу өчен комачауламаучы махсус шартлар тудырылырга тиешле физик зат.

1.3. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларына җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программаларын (алга таба - җайлаштырылган белем бирү программасы) үзләштерүче мөмкинлекләре чикләнгән укучылар һәм инвалид балалар ике тапкыр бушлай туклану алу хокукына ия.

1.4. Җайлаштырылган белем бирү программасы - мөмкинлекләре чикләнгән затларны һәм инвалид балаларны, аларның психофизик үсеш үзенчәлекләрен, индивидуаль мөмкинлекләрен исәпкә алып, укыту өчен җайлаштырылган һәм кирәк булганда, әлеге затларның үсешен һәм социаль адаптациясен тәэмин итә торган белем бирү программасы.

1.5. Бушлай ике тапкыр туклану мөмкинлекләре чикле һәм инвалид балаларга бары тик укырга килгән (дәресләрдә) булган көннәрдә генә бирелә. Укулар (дәресләр) барган көнне, нинди дә булса сәбәпләр аркасында гомуми белем бирү учреждениесе ашханәсе эшләми икән, мөмкинлекләре чикле һәм инвалид балаларга коры паек бирелә.

Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында сәламәтлекләре чикләнгән һәм инвалид балаларны тукландыру гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру буенча санитар-эпидемиологик таләпләр һәм расланган менюга туры китереп оештырыла.

1.6. Өйдә белем алучы мөмкинлекләре чикле укучылар һәм инвалид балалар коры паек белән тәэмин ителәләр.

1.7. Ике тапкыр бушлай туклануны һәм коры паекларны акчалата компенсациягә алыштыру рөхсәт ителми.

1.8. Укучыларга бер үк вакытта бушлай яки ташламалы туклану бирү өчен нигез булган очракта, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының «4 һәм аннан да күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрдәге балалар өчен түләүсез туклануны оештыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 22.03.20021 ел, № 124 карары нигезендә, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 79 маддәсе, 7 пункты нигезендә укучыларга ата-ана (законлы вәкилләр) теләге буенча югарыда күрсәтелгән нигезләрнең берсе буенча туклану бирелә.

1.9. Ата-ана (законлы вәкил) физик мөмкинлекләре чикләнгән баланы һәм инвалид баланы ике тапкыр бушлай туклану белән тәэмин итүдән язмача баш тарткан очракта, бу укучыга мондый туклану мөмкинлеге бирелми.
1.10. Мөмкинлекләре чикләнгән һәм инвалид балаларга ике тапкыр бушлай туклану бирү турында мәгълүмат бирелергә тиеш һәм ул социаль тәэминатның Бердәм дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба - ЕГИССО) куллану ярдәмендә алынырга мөмкин.

II. Мөмкинлекләре чикле һәм инвалид балаларга ике тапкыр бушлай туклану бирү турында карар кабул итү һәм документлар тапшыру тәртибе

2.1. Мөмкинлекләре чикләнгән һәм инвалид балаларга ике тапкыр бушлай туклану бирү өчен ата-ана (законлы вәкил) гомуми белем бирү оешмасына: тәкъдим итә:

а) мөмкинлекләре чикләнгән һәм инвалид баланы ике тапкыр бушлай туклану белән тәэмин итү турында билгеләнгән формада гариза (1 нче кушымта)

б) укучының гомуми белем бирү оешмасында белем алу (җайлаштырылган белем бирү программасы буенча уку) өчен ПМПК (Үзәк яки территориаль)ның махсус шартлар булдыруга мохтаҗ булуы турында гамәлдәге бәяләмәсе;

в) гариза бирүченең шәхесен раслаучы документ күчермәсе;

г) гариза бирүченең һәм мөмкинлекләре чикләнгән һәм инвалид баланың СНИЛС күчермәсе.

2.2. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле булган һәм инвалид балага ике тапкыр бушлай туклану бирү өчен әлеге Тәртипнең 2.1. пунктында күрсәтелгән кирәкле документларның тулы булмаган пакетын тапшыру документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып тора.
2.3. Сәламәтлекләре чикләнгән балаларга түләүсез ике тапкыр бушлай туклану бирү турындагы карар гомуми белем бирү оешмасы боерыгы белән әлеге тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырганнан соң өч эш көне эчендә рәсмиләштерелә.

Бушлай ике тапкыр туклану мөмкинлекләре чикле һәм инвалид балаларга белем бирү оешмасы боерыгы чыккан көннән соң килүче уку көненнән башлап уку елы ахырына кадәр, ләкин ПМПКда күрсәтелгән сроктан да артмаган вакытка бирелә.
2.4. Сәламәтлекләре чикле булган һәм инвалид баланы ике тапкыр бушлай туклану белән тәэмин итү хокукы ел саен ата-ана (законлы вәкил) тарафыннан гомуми белем бирү оешмасына 2.1 пунктында күрсәтелгән документлар пакетын тапшыру юлы белән раслана.
2.5. Мөмкинлекләре чикләнгән һәм инвалид балага ике тапкыр бушлай туклану тәкъдим итүдән баш тарту өчен нигезләр:

а) укучыларны ике тапкыр бушлай туклану белән тәэмин итү хокукын туктатуга китерә торган очракларны ачыклау;

б) мөмкинлекләре чикле һәм инвалид балаларның гомуми белем бирү оешмасыннан китүе.

2.6. Мөмкинлекләре чикләнгән һәм инвалид балаларга ике тапкыр бушлай туклану бирү гомуми белем бирү оешмасы боерыгы белән билгеләнгән көннән туктатыла.

III. Мөмкинлекләре чикләнгән һәм инвалид балаларга бушлай туклану бирүне оештыру

3.1. Физик мөмкинлекләре чикләнгән укучыларга һәм инвалид балаларга бушлай туклану бирүне оештыру өчен гомуми белем бирү оешмасы:
3.1.1. мөмкинлекләре чикләнгән һәм инвалид балаларга ике тапкыр бушлай туклану бирү тәртибе һәм шартлары турында ата-аналарга (законлы вәкилләргә) мәгълүмат бирүне тәэмин итә;
3.1.2. әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итә, документлар пакетын формалаштыра һәм аларны саклауны тәэмин итә;
3.1.3. укучының ике тапкыр бушлай туклану алу хокукын тикшерә;
3.1.4. укучыларга ике тапкыр бушлай туклану бирү (бирүдән баш тарту) турында Карар кабул итә;

3.1.5. мөмкинлекләре чикле һәм инвалид балалар, шул исәптән өйдә белем алучы укучылар исемлеген формалаштыра;
3.1.6. мөмкинлекләре чикләнгән һәм инвалид балаларга ике тапкыр бушлай туклану бирү буенча гамәлгә куючыга исәп-хисаплар төзүне һәм тапшыруны тәэмин итә;
3.1.7. мөмкинлекләре чикле укучыларны һәм инвалид балаларны бушлай ике тапкыр туклану һәм коры паеклар белән тәэмин итүне оештыра.
3.2. Мөмкинлекләре чикле балалар һәм инвалид балалар өчен ике тапкыр туклану (коры паек) бәясе башлангыч звено өчен 74,75 сум, 5-11 сыйныф укучылары өчен 1 уку көненә 54,20 сум исәбеннән айга бер тапкыр бозылмый торган азык-төлек (коры паеклар) белән тәэмин итүне оештырырга. Инвалид балалар һәм мөмкинлекләре чикле балалар өчен ике тапкыр туклануны оештыру мөмкинлеге булмаган очракта башлангыч звено өчен 55,55 сум, 5-11 сыйныф укучылары өчен 35 сум һәм иртәнге ашка 19,20 сум күләмендә коры паек бирү каралган.
3.3. Ата-аналар (законлы вәкилләр), гомуми белем бирү учреждениесе боерыгы белән билгеләнгән көнне балалары беркетелгән гомуми белем бирү оешмаларында айга бер тапкыр коры паеклар алалар.

IV. Мөмкинлекләре чикләнгән һәм инвалид балаларга бушлай ике тапкыр туклану бирү белән бәйле чыгымнарны финанс яклап тәэмин итү

4.1. Муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрендә физик мөмкинлекләре чикләнгән балаларга һәм инвалид балаларга түләүсез ике тапкыр туклану бирүгә бәйле чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итү тиешле финанс елына һәм планлы чорына Мөслим муниципаль районы мәгариф идарәсенең күрсәтелгән максатларына каралган бюджет ассигнованиеләре исәбеннән һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын тәэмин итүне ел саен индексацияләү турындагы карар”ы нигезендә гамәлгә ашырыла.
4.2. Муниципаль гомуми белем бирү учреждениесенә акча күләме мөмкинлекләре чикле балалар һәм инвалид бала категориясенә керүче укучылар санының фаразланган күләменнән һәм әлеге тәртипнең 3.2 пунктында билгеләнгән туклану бәясеннән чыгып билгеләнә.

V. Мөмкинлекләре чикләнгән һәм инвалид балаларга түләүсез ике тапкыр бушлай туклану бирү буенча контроль һәм җаваплылык

5.1. Гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесе мөмкинлекләре чикле һәм инвалид балаларга ике тапкыр бушлай туклануны оештыру буенча шәхси җаваплылык тота.
5.2. «Мөслим муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында физик мөмкинлекләре чикләнгән һәм инвалид балаларны бушлай туклану белән тәэмин итүгә каралган район бюджеты акчаларын максатчан куллануны контрольдә тота.